# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Татар Шуганы авылында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

**13 октябрь 2022 ел** **№1**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Уставы нигезендә 2022 елның 13 октябрендэ түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез, 2023 елда 1 төркем инвалидлар, Боек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

-җәйге чорда Татар Шуганы авылында территорияне чабу;

- Татар Шуганы авылында «Халыкара өлкәннәр көне», «Сабантуй» бәйрәм чараларын үткәрүне оештыру;

- трактор йөртүче хезмәте өчен түләү;

- Татар Шуганы авылы Сөембикә урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү) ;

- МТЗ-82.1 тракторы очен КУН-10 сатып алу;.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 258 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 158.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 158, «КАРШЫ» позициясе очен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре гамәлдә дөрес дип танырга.

2. Түбәнәге сораулар буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

«Сез, 2023 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп

төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

-җәйге чорда Татар Шуганы авылында территорияне чабу;

- Татар Шуганы авылында «Халыкара өлкәннәр көне», «Сабантуй» бәйрәм чараларын үткәрүне оештыру;

- трактор йөртүче хезмәте өчен түләү;

- Татар Шуганы авылы Сөембикә урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү) ;

- МТЗ-82.1 тракторы очен КУН-10 сатып алу;.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Татар Шуганы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Татар Шуганы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Татар Шуганы авыл җирлеге башлыгы ________________ М.Ш.Хәертдинов
(имза) (имза расшифровкасы)